| СОВЕТ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2022 елның 29 декабре № 24/6

**Гавами тәкъдим юлы белән муниципаль мөлкәтне сатуны оештыру турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 5 декабрендәге 512-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 29 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2017 елның 15 декабрендәге 22/5 номерлы (2019 елның 23 октябрендәге 38/3 номерлы редакциясендә) карары белән расланган гавами тәкъдим юлы белән муниципаль мөлкәтне сатуны оештыру турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**а) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«5. Гавами тәкъдим юлы белән сатуда катнашу өчен, дәгъвачы түбәндәге күләмдә алдан түләү кертә:

дәүләт яки муниципаль милекне сату турында мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән һәм 100 миллион сум һәм аннан да күбрәк сумманы тәшкил иткән башлангыч бәянең 20 проценты;

дәүләт яки муниципаль милекне сату турында мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән һәм 100 миллион сумнан ким булган башлангыч бәянең 10 проценты.»;

**б) киләсе эчтәлекле 5_1 пунктын өстәргә**:

«5_1. Мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән счетка алдан акча керүне раслаучы документ шушы счеттан өземтә булып тора.».

2. Әлеге карарны Чүпрәле муниципаль районы сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының Рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе М.Р. Гафаров